ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02 11 2020 г. № 848

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 8 августындагы 1309 номерлы карары белән расланган дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерциягә карамаган оешмаларга Түбән Кама муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр күләмен билгеләү һәм бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 8 августындагы 1309 номерлы карары белән расланган дәүләт (муниципаль) учреждени-еләре булмаган коммерциягә карамаган оешмаларга Түбән Кама муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр күләмен билгеләү һәм бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Бюджеттан субсидияләр күләмен билгеләү һәм бирү тәртибенең 2.5 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «2.5. Субсидия бирүнең мәҗбүри шарты булып, субсидияләр алучыларның һәм бюджет акчаларын баш бүлүче һәм дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүе органнары тарафыннан субсидия алучыларның субсидияләр алу шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыру өчен субсидияләр алучылар чыгымнарын финанс белән тәэмин итү турындагы шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булган затларның ризалыгы һәм, югары технологияле чит ил җиһазларын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (җибәргәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, шулай ук субсидия бирү тәртибен җайга салучы норматив хокукый актларда, муниципаль хокукый актларда,

Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы, җирле администрация карарлары белән билгеләнгән очракларда башка операцияләрдән тыш, алынган акчалар исәбеннән чит ил валютасын сатып алуны тыю тора».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Бюджет һәм финанслар департаменты җитәкчесе С.Н. Логиновага йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов